**Тема: Кушма сүзләр.**

**Максат:**

1. Кушма сүзләр турында мәгълүмат бирү. Кушма сүзләрдә нечкәлек билгесе (ь), калынлык билгесе (ъ) язылышын аңлату.
2. Кушма сүзләрне аера, дөрес яза, җөмләдә куллана белергә өйрәтү.
3. Гореф-гадәтләребезгә сакчыл караш, хөрмәт тәрбияләү.

**Дәрес барышы:**

**I.Оештыру**

**- Хәерле көн, дуслар сезгә!**
**Хәерле көн, һәммәгезгә!**
**Татар телен өйрәнүдә**
**Уңышлар телим сезгә.**
**Бер-беребезгә карап елмайыйк та,**
**Яхшы кәеф телик дусларга.**
**Хәерле көн, хәерле юл телик,**
**Белем иле буйлап узарга.**

II. **Белемнәрне актуальләштерү.**

- Укучылар, әлеге рәсемгә карагач, нинди бәйрәм күз алдыгызга килеп басты?

**Слайд №1**

- Әйе, әлбәттә инде, Сабан туе! Сабан туе - халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, җырлары һәм биюләре бергә кушылган хезмәт бәйрәме. Бәйрәм атамасы борынгы төрки “сабан” һәм “туй” сүзләреннән килеп чыккан.

- Сез дә, балалар, бу бәйрәмне көтеп аласызмы?

- Әйе, сез генә түгел бөтен татар халкы көтеп аладыр ул ямьле бәйрәмебезне. Шулай булгач, әйдәгез, туган ягыбызда салкын кыш булуга карамастан, үзебезне җәй көнендәге кебек хис итеп, дәресебездә Сабан туен үткәрик әле. Барыбыз да Сабан туенда уйнала торган уеннарда катнашырбыз,

шул ук вакытта өйрәнәчәк тема буенча белемнәр дә тупларбыз. Сез ризамы? Алайса, Сабан туен башлап җибәрәбез! (Айдар Файзрахманов башкаруында “Сабан туе” җыры яңгырый)

Сабан туе белән бергә халкыбызның күпме уеннары, күпме физик күнегүләре саклап калынган. Мәйданга килгән һәр кеше җан рәхәте, рух сихәте алган. Дус-туганнарың белән очрашу, кызыклы уеннар уйнау, җырлап-биеп күңел ачу, тәмле ризыклар белән сыйлану һ.б, һ.б урыны да ул. Шулай бит, дусларым? Ә менә авылдаш, кунак, эшче, сүз, уенчык, каенлык, кашык, алмагач, чиләк, ат, сөенче кебек сүзләрне Сабан туенда да ишетәбез. Әйдәгез, бу сүзләрне ясалышлары буенча төркемләп карыйк әле.

**Слайд №2**

- Нинди төркемнәр килеп чыкты? Беренче төркемгә тамыр сүзләрне (кунак, сүз, кашык, чиләк, ат), ә икенче төркемгә ясалма сүзләрне (авылдаш, эшче, уенчык, каенлык, сөенче) кертергә мөмкин. Алар тамыр һәм ясагыч кушымчадан тора. Артып калган сүз бармы? Әйе, алмагач. Ә бу сүз ничек ясалган соң? Алма һәм агач сүзләре кушылып алмагач сүзе килеп чыккан. Бу сүз ике тамырдан тора. Мондый сүзләрне ничек атала икән? Телебездә алар күп микән? дигән сорауларга җавапларны Сабан туебызның уеннарында табарбыз. Ә хәзер, сезне күз бәйләүле килеш баудан әйберләр кисеп алу уенына чакырам.

**Слайд №3**

- Табышмакларны чишсәк, теләгән бүләгебезне дә алырбыз. Башладык!

**III. Яңа материал буенча эш.**

**Слайд №4**

1.Түп-түгәрәк кара күз.

Сап-сары керфекләре.

Ул ярата кояшны

Без - аның бөртекләре (көнбагыш) Афәрин, бүләккә көнбагыш!

2. Ятса- таш,

Якса- утын.( ташкүмер) Нинди генә бүләкләр юк бу Сабан туенда! Ташкүмер. Өлешеңә тигән көмешең инде.

3) Тышы кабык, эче мамык. Гөлҗимеш. Файдалы бүләк иясен котлыйбыз!

4) Бер карасаң, тышта йөри,

Бер карасаң йортта ул.

Йортым ерак калмасын, дип,

Аркасында йөртә ул. (ташбака) Бүгенге Сабан туенда бүләккә, хәтта ташбака да бар!

5) Ахыргы сорау-табышмак – ул кыз исеме. 1нче тамыры-үсемлек, 2се – аңа үсәргә ярдәм итүче чыганак (Гөлнур) Котлыйбыз! Бигрәк матур гөлгә ия булды Гөлнур.

Игътибар иткән булсагыз, табышмакларның җаваплары, ягъни бүләкләребезнең исемнәре - барысы да нинди сүзләр булып чыкты? Нәкъ шулай, кушма сүзләр.

**Слайд №5**

- Ә нинди сүзләргә без кушма сүзләр дип әйтәбез соң?

**Слайд №6**

Әйе, бик дөрес! **Ике сүз кушылып ясалган сүз кушма сүз дип атала. Кушма сүзләр һәрвакыт бергә языла, бер мәгънә белдерә, бер басым белән әйтелә.**

**Слайд №7-10**

**Мәсәлән:** төн+боек, оек+баш, яр+канат, озын+борын.

Ә үзегез тагын нинди кушма сүзләр беләсез?

- Афәрин, балалар! Ул арада Сабан туебыздагы **“Колга башына менү” уены** башланып та киткән. Ай-һай, уен микән колга башына менү?

**Слайд № 11**

Озын гына шоп-шома

Бер багана бар шунда

Әтәч тора әйләнгәләп,

Шул багана башында.

Әтәчкә шук малайлар

Әй кызыгып карыйлар,

Багана шома булганга

Бер дә менә алмыйлар.

- Бәлки сез менә алырсыз? Кем җитез? Кем өлгер? Әтәч аягындагы сорауга җавап бирсәгез, димәк, сез колга башына менгәнсез дигән сүз. Сорау шул: телебезгә рус теленнән кергән кушма сүзләр бармы? Я, кайсыгыз? *(Укучылар*

*кушма сүзләр әйтәләр*: пароход, теплоход, самовар, самолёт, автовокзал, автозавод, автомашина, километр, сантиметр, килограмм.*)*

**Слайд №12**

- Рәхмәт, бик күп кушма сүзләр беләсез икән, дуслар. Сез колга башында.

**Слайд №13**

**Инде тагын бер кагыйдәне искә төшерик: ике тамыр сүз кушылып яңа сүз ясалганда икенче тамыр ю, е, я авазларына башланса, бу сүзләр арасына ь һәм ъ билгеләре куела.** Мәсәлән, көньяк дигән сүздә нинди билге куелырга тиеш. Ни өчен? Әйе, ь билгесе куела.

Бик дөрес, **әгәр сүзнең беренче иҗеге калын булса - ъ, ә нечкә булса - ь билгесе куела**. Мәсәлән: алъяпкыч, төньяк, кулъяулык, берьюлы һ.б.

Инде белемнәребезне ныгытып куйыйк:

Бергә-берне кушкач ничә,
Беләм: ике диярсез.
Сүзгә-сүзне кушкач:
Анысы нәрсә дигән сүз?
Миңа кирәк ике сүз,
Шуннан ясыйм (кушма) сүз.
Карагыз минем көчкә:
Алам “ак”ны-төс бит ул,
Канатлы дус-“кош”бит ул;
“Ак”ны кушкач шул “кош”ка
“..........”дигән дус чыга.

*(Укучылар аккош, кушма сүзләрен үзләре әйтәләр)*

**Слайд №14**

- **“Катыктан акча эзләү” Сабан туеның иң кызыклы уеннарының берсе.**

**Слайд №15**

- Без дә тәмле катыктан да авыз итик, белемнәрне дә ныгытыйк әле.

Катыктагы акчаны абыйлар тырышып эзләгән кебек, сезгә дә хәзер экранда күрсәтеләчәк рәсемнәрне берләштереп, яңа сүзләр ясарга кирәк булыр. *(Рәсемнәр күрсәтелә, укучылар кушма сүзләр ясыйлар).* Нинди сүзләр килеп чыкты? Дөрес. Ташбака, юлбарыс, карабүрек.

**Слайд №16-18**

Сабантуй кызганнан кызганнан-кыза бара бит, дусларым. Биремнәр дә бераз катлаулана: хәзер инде бер төркем рәсемнәр арасыннан бер-берсенә туры килгән сүзләрне табып, кушма сүзләр ясап карыйк. Ягез, кем тизрәк?

**Слайд № 19-22**

- Үз-үзебезне тикшерик: гөлчәчәк, ашъяулык, алмагач, унике. Молодцы!
- Тик нинди бәйрәм җыр-биюсез узсын инде, дуслар?!

Сабантуй ул – күңел ачу,
Уен, шатлык бәйрәме.
Җырлар җырлап биеп алыйк,
Шау-гөр килеп, әйдә әле!

**Тиззарядка** (татар биюе башкарыла)

**Слайд №23**

- Бию барышында мин сезгә сораулар әйтәм, көй туктагач, шул сораудагы җавап санынча сезгә берләшергә кирәк. Мәсәлән, ике-икең ничә? Дүрт. Димәк, сез дүрт кеше бергә тупланырга тиешсез. Башладык.

***Сораулар:*** *- Кушма сүз ничә сүз кушылып ясала? (ике)*

- *Аккош сүзендә ничә хәреф?*
- *Өчпочмакта ничә почмак?*
- *Тимеркапка ничә иҗектән тора?*
- Бик яхшы, булдырдыгыз, дуслар. Бераз ял да итеп алдык. Ә хәзер барыбыз да **"Ат чабышы"** ярышында катнашырбыз.

Кем биремне дөрес һәм тизрәк үти, шуның аты беренче килә.

Сабан туенда уеннар
Төрле була, күп була.
Уеннарсыз Сабан туе
Булмаган да күк була.

**Слайд № 24**

- Сүзләрне туры китереп, кушма сүзләр ясарга. Таләп шундый: сүзләрне

парлаштырганда, аларның мәгънәсе булырга тиеш.

Иң бау

Китап жимеш

Көн озын

Бил баш

Гөл көмеш

Тере ханә

**Слайд №25**

- Тикшереп үтик: иңбаш, көнозын, билбау, гөлҗимеш, терекөмеш, китапханә. Атларыгыз бик җитез икән, дуслар!
- Сабан туеның төп бизәге ул нәрсә дип сорасам, һич икеләнүсез татарча көрәш дип җавап бирербез.

**Слайд № 26**

Игътибарны юнәлтик,

Уртага, зур мәйданга,

Озакламый бик күңелле

Көрәш булачак анда.

Көрәшәчәк батырлар,

Кем көчле, зирәк, елгыр?

Кем күбрәк мисал китерә,

Шул булыр бүген батыр!

- Әйе, безнең көрәшебез белем мәйданында, дуслар. Көрәштә дә сынатмыйк! Кушма сүзләргә ъ һәм ь билгеләрен дөрес итеп куйыйкчы:

**Слайд № 27**

**Ал+япкыч, шәл+яулык, бер+юлы, йөз+яфрак, дөн+я, көн+як, кул+яулык, төн+як, өч+яклы, һәр+яклап, Таш+елга, Кызыл+яр, Ях+я, Дүрт+яклы, тигез+ янлы.**

Экранда күрсәтелгәнчә язган булсагыз, сез – җиңүче!

**IV.Йомгаклау**

- Шулай итеп, күп гасырлы тарихы булган татар Сабан туе жирдәге һәр

халыкны чакырып, күңелен күтәрә, җанына җылы бирә, шатлык өсти торган күркәм бәйрәм. Бүгенге дәресебездә сез дә шул матур хисләрне кичергәнсез,

кирәкле белемнәр дә туплагансыз дигән өмет белән, киләсе очрашуларга кадәр саубуллашам. Исән-имин булыйк, дуслар!